“Килешенде”
МБ җитәкчесе
________Г.Г.Фатхуллина
Беркетмә №__1____
“25 ” __08__ 2021 нче ел

“Килешенде”
Милли мәгариф буенча
директор урынбасары:
___________Л.К. Миннубаева
“25 ” __08__ 2021 нче ел

“Раслыйм”
“П.А. Полушкин исемендәге
101 нче мәктәп” директоры
___________Т.Н.Петрова
Приказ № 78
“28 ”__08__ 2021 нче ел

Казан шәһәре Совет районы “П.А.Полушкин исемендәге 101 нче гомуми белем мәктәбе – Мәгариф үзәге”
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе

Дәрестән тыш эшчәнлек

# *Әдәби уку фәне буенча дәрестән тыш эшчәнлек өчен төзелгән эш программасы*
# *( 1 – 4 нче сыйныфлар).*
# *МИЛЛИ ХӘЗИНӘ*

(социаль юнәлеш)

Төзүчеләр:
Фәтхуллина Галия Гаптелвәли кызы,
беренче категорияле туган теле һәм әдәбияты укытучысы
Рахимова Гульгена Вадут кызы,
беренче категорияле туган теле һәм әдәбияты укытучысы

Педсовет утырышында
каралды
Беркетмә №__1____
“25 ” __08__ 2021 нче ел

2021/2022 нче уку елы

## Көтелгән нәтиҗәләр

| Бүлекләр | Предмет нәтиҗәләре | Метапредмет нәтиҗәләре | Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|
| **Балалар фольклоры.**<br><br>**Татар халык әкиятләре.**<br><br>**Мәзәкләр**.. | **Танып-белү өлкәсендә:**<br>— төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;<br>— сәнгатьле уку;<br>— шигъри кабатлап сөйләүнең төрле төрләреннән файдалану (**тулы** итеп, кыскача, сайлап, аңлатмалар белән, иҗади бирем белән);<br>— текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү; әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү;<br>— план төзү;<br>— әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, тулы яки мини -сочинение язу;<br>— укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру;<br>— өстәмә белем чыганакларыннан язучыларның тормышы һәм иҗаты турында белү; | **Метапредмет нәтиҗәләр** дигәндә реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен ***(регулятив, коммуникатив, танып-белү)*** күз алдында тотабыз. Бу **гамәлләр уку эшчәнлеген оештыруның һәм компетенцияләр формалаштыруның нигезе** булып тора. Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль **һәм** иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә.<br>**Предметара төшенчәләрне** формалаштыру да **метапредмет** нәтиҗәләр яссылыгына куела.<br>*Метапредмет* (танып-белү, регулятив, коммуникатив) *нәтиҗәләр:*<br>**танып-белү:**<br>- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;<br>- классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;<br>- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру; | — шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күп-милләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;<br>— активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;<br>— үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;<br>— милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Татар халык җырлары.**<br>**Татар халык бәйрәмнәре.**<br>**Татар исемнәре.**<br>**Милли киемнәр**<br>**Өстәл әдәбе.** | — татар әдәбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре,аларның иҗаты турында белү;<br>**Әхлакый кыйммәтләр юнәлеше өлкәсендә:**<br>татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту, башка халыкларныкы белән чагыштыру;<br>татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү;<br>өйрәнелгән әдәби әсәрләргә аерым очракларда үзгәреш кертә белү;<br>автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау.<br>**Коммуникатив өлкәдә:**<br>— төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау;<br>— чәчмә әсәрләрне яки өзекләрне татар теленең әдәби чараларын һәм цитаталарын кулланып сөйли белү, укыган яки ишеткән текст буенча сорауларга җавап бирә алу, телдән төрле типтагы монолог, диалоглар | - үрнәк буенча эшли белү;<br>- аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;<br>- рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;<br>- аңлап укый белү;<br>- укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;<br>**регулятив:**<br>- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;<br>- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;<br>- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;<br>- уку хезмәтенә бәя бирә белү;<br>- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;<br>- укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;<br>- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;<br>- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;<br>**коммуникатив:**<br>- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый һәм аралаша белү | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Татар телендә нәшер ителүче балалар журналлары.** | төзү, әңгәмә кору;<br>**Эстетик өлкәдә:**<br>— әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әсәрләрдән рухи тәм табу;<br>— сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образлар тудырганда сурәтләү көчен аңлау. | күнекмәләрен формалаштыру;<br>- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);<br>- парларда һәм күмәк төркемнәрдә эшли белү;<br>- әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү. | |
| **Иҗади эшләргә корылган дәресләр** | | | |

**Программаның эчтәлеге**

| № | Тема | 1 сыйныф | 2 сыйныф | 3 сыйныф | 4 сыйныф |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | **Балалар фольклоры.** | 8 | 5 | 6 | 6 |
| 2. | **Татар халык әкиятләре.** | 5 | 5 | 5 | 4 |
| 3. | **Мәзәкләр**.. | 1 | 2 | 2 | 2 |
| 4. | **Татар халык җырлары**. | 3 | 3 | 3 | 3 |
| 5. | **Татар халык бәйрәмнәре.** | 2 | 3 | 2 | 2 |
| 6. | **Татар исемнәре.** | 2 | 3 | 2 | 3 |
| 7. | **Милли киемнәр** | 2 | 3 | 3 | 4 |
| 8. | **Өстәл әдәбе.** | 5 | 3 | 4 | 4 |
| 9. | **Татар телендә нәшер ителүче балалар журналлары.** | 2 | 3 | 2 | 2 |
| 10 | **Иҗади эшләргә корылган дәресләр** | 3 | 4 | 5 | 4 |
| | | 33 | 34 | 34 | 34 |

**1. Балалар фольклоры.**

Балалар фольклоры турында төшенчә бирү, китаплар белән таныштыру. Тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар, хәрәкәтле такмаклар,мәкальләр җыю. (Хәрәкәтле такмакларның максаты – авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, хәрәкәтләрне такмаклау гамәле белән координацияләү, хәрәкәтләр сайлаганда балаларга иҗат өчен мөмкинлекләр бирү, оялу, киеренкелек хисеннән котылу өчен шартлар тудыру).

**2. Татар халык әкиятләре.**

Татар халык әкиятләре белән танышу. Әкият сайлап алып сәхнәләштерү яки курчак театры оештыру, түгәрәк җитәкчеләре белән элемтәдә булу.

**3. Мәзәкләр**. Татарча мәзәкләр уку.

**4. Татар халык җырлары**.

Татар халык җырлары белән танышу. Музыка укытучылары Мөхәммәдиева Л. Б. һәм Әбелханова Э. М. белән тыгыз элемтәдә эшләү.

**5.Татар халык бәйрәмнәре..**

Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү. “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Сабантуй” бәйрәмнәрен үткәрү өчен әзерлек эшләре алып бару.

**6.Татар исемнәре**

Кайбер татар исемнәре белән танышу. Мәгънәләрен билгеләү. Шәҗәрә төзү. Тарих һәм әдәбият укытучылары белән берлектә эшләү.

**7.Милли киемнәр.**

Татар халкының милли киемнәре белән таныштыру. Кием әдәпләре турында әңгәмә оештыру. Технология укытучысы Ибраһимова Н.Х. белән берлектә проект эшләре төзү.

**8.Өстәл әдәбе.**

Татар халык ашлары турында әңгәмә оештыру. Табын әдәпләре. Кунак чакыру, кунакка бару темасына диалоглар. Мәктәп ашханәсе пешекчесе Садрыева Р.М. белән тыгыз элемтәдә булу.

**9.Татар телендә нәшер ителүче балалар журналлары.**

“Сабыйга”, “Салават күпере” журналлары белән таныштыру, мөхәррирләр белән очрашу, иҗади эшләрне бастыру.

**10.Иҗади эшләргә корылган дәресләр** бәйрәмнәр үткәрүгә, яисә эзләнү, фәнни-тикшеренү эшен оештыруга бирелә.

**Тематик планлаштыру.**

**1 нче сыйныф – 33 сәгать.**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. | 1 |
| 2 | Табышмаклар | 1 |
| 3 | Тизәйткечләр | 1 |
| 4 | Әйтешләр. Әйтемнәр. | 1 |
| 5 | Мәкальләр. | 1 |
| 6 | Санамышлар. | 1 |
| 7 | Сынамышлар | 1 |
| 8 | Татар халык уеннары. | 1 |
| 9 | Уйныйбыз да, җырлыйбыз да... | 1 |
| 10 | Тормыш-көнкүреш әкиятләре | 1 |
| 11 | Тылсымлы әкиятләр | 1 |
| 12 | Тылсымлы әкиятләр | 1 |
| 13 | Хайваннар турындагы әкиятләр | 1 |
| 14 | “Әкият”тә кунакта. | 1 |
| 15 | Көлке көлә килә, арттан куа килә. | 1 |
| 16 | Татар халык җырлары. | 1 |
| 17 | Кызлар исеменә багышланган җырлар | 1 |
| 18 | Җырларга мин бик оста. | 1 |
| 19 | Татар халык бәйрәмнәре | 1 |
| 20 | Сабантуйга барабыз | 1 |
| 21 | Исемең матур, кем кушкан? | 1 |
| 22 | Минем гаиләмдәге исемнәр. | 1 |
| 23 | Милли киемнәр белән танышу | 1 |
| 24 | Милли киемнәр рәсемдә | 1 |
| 25 | Өстәл янында үз – үзеңне тоту кагыйдәләре. | 1 |
| 26 | Ашау әдәбе. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 27 | Табын әзерләү серләре | 1 |
| 28 | Татар халык ашлары | 1 |
| 29 | Татар халык ашлары | 1 |
| 30 | Гаилә бәйрәме | 1 |
| 31 | Татар телендә нәшер ителүче журналларга күзәтү | 1 |
| 32 | “Сабантуй”да кунакта | 1 |
| 33 | Иҗади дәрес. | 1 |

**2 нче сыйныф – 34 сәгать.**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Хәрәкәтле такмаклар. | 1 |
| 2 | Әйтем-сүзнең бизәге. | 1 |
| 3 | Хикмәтле сүзнең бер төре – мәкаль. | 1 |
| 4 | Чагыштыру, табышмаклар. | 1 |
| 5 | Сынамышлар, санамышлар. | 1 |
| 6 | Әкиятләр безне нәрсәгә өнди? | 1 |
| 7 | Татар халык әкиятләре. Алдавычлар. | 1 |
| 8 | Әкиятләрнең төрләре. | 1 |
| 9 | Кем әкият укый белә? | 1 |
| 10 | Әкият бездә кунакта! | 1 |
| 11 | Иҗади дәрес. Әкиятләр кичәсе. | 1 |
| 12 | Мәзәкләрнең кеше тормышындагы роле. | 1 |
| 13 | Мәзәк сөйлим, син тыңла! | 1 |
| 14 | Җырсыз, моңсыз кеше яши алмый. | 1 |
| 15 | Җырлы – биюле уеннар. | 1 |
| 16 | Әбием янчыгыннан. (Борынгы татар халык җырлары) | 1 |
| 17 | Җырчы гаиләләр бәйгесе. | 1 |
| 18 | Бәйрәмнәр кирәк һәммәбезгә дә... | 1 |
| 19 | “Нәүрүз” бәйрәме кайчан үткәрелә? | 1 |
| 20 | Безнең гаиләдә бәйрәмнәр ничек үтә. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 21 | Исеменә күрә җисеме. | 1 |
| 22 | Борынгы һәм яңа исемнәр. | 1 |
| 23 | Борынгы һәм яңа исемнәр. | 1 |
| 24 | Бабамның түбәтәе, әбиемнең калфагы. | 1 |
| 25 | Төсле кәгазьдән аппликация. “Читек” | 1 |
| 26 | Заманча милли кием. | 1 |
| 27 | Мәктәп ашханәсендәге милли ризыклар. | 1 |
| 28 | Кунак ашы – кара-каршы. Табын әдәбе. | 1 |
| 29 | Минем әнием – татар халык ашлары остасы! | 1 |
| 30 | Мин – нәни пешекче! (Иҗади дәрес) | 1 |
| 31 | Балалар журналы ничек барлыкка килә? | 1 |
| 32 | “Салават күпере” – иң кызыклы журналларның берсе! | 1 |
| 33 | Минем беренче шигырем. | 1 |
| 34 | Иҗади дәрес. | 1 |

**3 нче сыйныф – 34 сәгать.**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Балалар фольклоры нәрсә турында сөйли? | 1 |
| 2 | Синең телең баймы? | 1 |
| 3 | Тапкырга - табышмак. | 1 |
| 4 | Татар халык сынамышлары. | 1 |
| 5 | Тематик мәкальләр җыю. | 1 |
| 6 | Бәетләр. | 1 |
| 7 | Әкиятләр. Аларның төрләре. | 1 |
| 8 | Әкиятне ничек башларга һәм ничек тәмамларга? | 1 |
| 9 | Әкият язам утырып, кәгазь битен тутырып. | 1 |
| 10 | Әкиятләр уку бәйгесе. | 1 |
| 11 | Без – нәни артистлар! | 1 |
| 12 | Без – нәни артистлар! | 1 |
| 13 | Сүз куәте нинди була? Мәзәкләрне урынлы куллану. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | Хуҗа Насретдин кем ул? | 1 |
| 15 | Кем катырак көлдерер? (Көлдергечләр уку бәйгесе.) | 1 |
| 16 | Җыр – кемнәрнең иҗат җимеше? | 1 |
| 17 | Татар халык җырларында кеше исемнәре. | 1 |
| 18 | Татар халык җырларында кеше исемнәре. | 1 |
| 19 | Татар халык бәйрәмнәре. | 1 |
| 20 | Татар халкының дини бәйрәмнәре һәм йолалары. | 1 |
| 21 | Гаилә бәйрәме “Аулак өй” | 1 |
| 22 | Татар халкында исем кушу йоласы. | 1 |
| 23 | Борынгы исемнәр тарихы. | 1 |
| 24 | Милли киемебезне бизәүче элементлар. | 1 |
| 25 | Мәктәп музеена экскурсия. | 1 |
| 26 | Курчакка милли күлмәк тегү. | 1 |
| 26 | Курчакка милли күлмәк тегү. | 1 |
| 28 | Татар халык ашларының күптөрлелеге. | 1 |
| 29 | Кунак булсаң, тыйнак бул! | 1 |
| 30 | Кунакларны каршы алу һәм озату. | 1 |
| 31 | Күчтәнәч серләре. | 1 |
| 32 | “Ялкын” журналы - минем дустым! | 1 |
| 33 | Почта бүлегенә вертуаль экскурсия. Балалар өчен иҗат ителгән газета-журналлар | 1 |
| 34 | Йомгаклау дәресе. | 1 |

**4 нче сыйныф – 34 сәгать.**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Тизәйткеч – тел шомарткыч. | 1 |
| 2 | Эндәшләр. | 1 |
| 3 | Халык әйтсә, хак әйтә! (Мәкаль, әйтем, сынамышлар.) | 1 |
| 4 | Куен дәфтәре ясау. (Иң кызыклы табышмаклар җыелмасы.) | 1 |
| 5 | Бәетләр. | 1 |
| 6 | Такмаклар, такмазалар. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | Әкият – минем балачак дустым! | 1 |
| 8 | Әкияттәге уңай һәм тискәре образлар. | 1 |
| 9 | “Кем күбрәк белә?” (Татар халык әкиятләре буенча уен - дәрес.) | 1 |
| 10 | Казан шәһәре курчак театрына вертуаль экскурсия. | 1 |
| 11 | Хикмәтле сүз- мәзәк. | 1 |
| 12 | Көлегез, көлегез, файдасы күп, белегез! | 1 |
| 13 | Моң керде күңелләргә! Татар халык җырлары. | 1 |
| 14 | Татар халык җырларын башкаручы артистлар. | 1 |
| 15 | Татар халык җырларын башкаручы артистлар. | 1 |
| 16 | Һәр халыкның үз бәйрәме. | 1 |
| 17 | “Каз өмәсе”. презентация | 1 |
| 18 | Без бәйрәм яратабыз. Рәсем конкурсы | 1 |
| 19 | Заманча исемнәр модасы. | 1 |
| 20 | Булачак баламның исеме нинди булыр һәм ни өчен? | 1 |
| 21 | Гаиләм шәҗәрәсе. Әби-бабаларым ни атлы булган? (Әңгәмә) | 1 |
| 22 | Гаиләм шәҗәрәсе. Әби-бабаларым ни атлы булган? (Проект) | 1 |
| 23 | Татар халык киемнәрендә орнаментлар. | 1 |
| 24 | Татар халкының бизәнү әйберләре. | 1 |
| 25 | Мин – дизайнер! “Киләчәк буынга заманча милли кием” | 1 |
| 26 | Мин – дизайнер! “Киләчәк буынга заманча милли кием” (рәсемнәр) | 1 |
| 27 | Милли музейга вертуаль экскурсия. | 1 |
| 28 | Милли ризыкларларның төрлелеге.. | 1 |
| 29 | Милли ризыкларның файдасы һәм зарары. | 1 |
| 30 | Татар халык ашлары | 1 |
| 31 | Татар халык ашлары | 1 |
| 32 | Газета, журнал битләрендә үз мәкаләләреңне күрү өчен нишләргә кирәк? | 1 |
| 33 | Безнең иҗат җимешләребез. | 1 |
| 34 | Без нәрсәләргә өйрәндек? Йомгаклау дәресе. | 1 |